шәһәребез кешеләре

## Рәкит ӘБДЕЛМАНОВ:
# “АРТКА ЮЛ ЮК”

**Шәһәр хакиме Илдар Халиков “Идел-Урал” хәйрия фонды учредителе Рәкит Әбделмановны күркәм юбилее белән тәбрик итте. Һәм озак еллар хәйриячелек эшчәнлеге алып барган, инвалидларны актив тормышка җәлеп иткән юбиляр “Чаллы шәһәре каршында күрсәткән хезмәтләре өчен” билгесе белән бүләкләнде. Мактаулы исемнән һәм күкрәк билгесеннән тыш Рәкит Әбделмановка хаким истәлекле бүләк — хәнҗәр тапшырды.**

Ризидә РӘХМӘТУЛЛИНА

Үзенең юбилей кичәсен Рәкит Әбделманов Сара Садыйкова исемендәге концерт залында билгеләп үтте. Кемнең-кемнең, әмма Рәкит Әбделмановның эшчәнлеге халыкка билгесез түгел. Ул учредительлек иткән “Идел-Урал” хәйрия фонды 15 ел эчендә Россия буйлап барлыгы 10 автосәфәр оештырды. 1997 елда инвалид спортчылар Чаллыда билгеле шәхес — Дени Абрамашвили ярдәме белән Кавказга кадәр барып җиттеләр. 2004 елда “Терроргa — юк” дигән девиз астында 7 көн эчендә 2 мең километр юл узып, Мәскәүне әйләнеп кайттылар. Юбиляр һәм аның эше турында сөйләгәндә, “Идел-Урал”ның шахмат-шашка клубы белән актив хезмәттәшлек итүен дә (биредә инвалидлар арасында да турнирлар үткәрелә), инвалид спортчыларның Россиякүләм бәйгеләрдә актив катнашып килүен дә әйтеп узарга кирәк. Чаллыда инвалидлар Сабан туйлары оештыру да “Идел-Урал” хәйрия фонды инициативасы белән традициягә керде.

Рәкитнең инвалид спортчыларны берләштерүе исә очраклы түгел. Ул үзе дә спортчы. Армспорт буенча инвалидлар арасында узган Россиякүләм бәйгедә — III, республикакүләм фестивальдә шашка буенча — III, теннис буенча II урыннарны яулаган. Рәкит Әбделмановның 2009 елда “Алтын йөрәкле кеше” бәйгесендә җиңү яулавын һәм Татарстанда “Ел хәйриячесе” исеменә лаек дип табылуын да әйтеп узу урынлы булыр.

Кичәнең үзенчәлекле ягы шунда — ул Рәкит Әбделмановның ярдәмен тоеп яшәгән инвалидларны да, юбилярның хезмәтен таныган дәрәҗәле кунакларны да үзенә җыйган иде. Күптән түгел “Идел-Урал” фонды Россиякүләм бәйгедә җиңү яулап, 10 миллион сумлык грант отты һәм шуның белән кризис шартларында эштән кыскартылганнарга ярдәм итү мөмкинлегенә ия булды. Шул уңайдан Россия Федерациясе милли хәйрия фондының региональ бүлеге җитәкчесе Юрий Остроумов юбилярга җиңүче таныклыгы тапшырды. Рәкит Әбделмановны ТР Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының Чаллы идарәсе башлыгы Гөлнар Әхмәтова, шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Галина Каширина, шәһәрне яшелләндерү хуҗалыгы башлыгы Сәлим Хәбибуллин, “Камгэсэнергострой” ААҖ генераль директоры урынбасары Салихҗан Гайниевлар да тәбрикләде. Рәсми кунаклардан тыш, сәхнәгә Галиәхмәт Шаһи, Роза Хәмидуллина кебек иҗат кешеләре дә (Рәкит үзе дә күп кенә шигырьләр, хикәяләр авторы), инвалид спортчылар да күтәрелде. Инвалидлар арасында шахмат буенча дөнья чемпионы Станислав Михеев инвалид спортчыларны оештырып, үз артыннан ияртә алганы өчен Рәкит Әбделмановка рәхмәт белдерде. Инвалид спортчылар юбилярның максатчан кеше булуын билгеләп үттеләр. “Рәкит оештырган чараларда беренчеләрдән ...” берниндиә өзеклек килеп чыкмый, — дип сөйләде Фәнис Нуретдинов. — “Назад хода нет” — бу юбилярның яраткан сүзе”.



Юбилярны тәбрикләргә аның якташлары — “Шоңкар” башкорт җәмгыяте каршында эшләүче “Гөлнәзирә” ансамбле дә килгән иде. Рәкит Әбделманов тумышы белән Башкортстанның Күмертау районыннан. Хатыны Гөлчирә белән алар Артур исемле егет тәрбияләп үстергәннәр...

Илле яшь ул әле күп түгел. Рәкит Җәүдәт улы кебек тынгысыз, актив кеше өчен — бигрәк тә. Бүген ул шәһәрдә инвалидлар өчен махсус спорт комплексы төзү идеясе белән йөри. Шәһәр җитәкчелеге тәкъдимне хуплаган, проект әзерләнә, инвесторлар белән сөйләшүләр алып барыла. Рәкит Әбделманов фикеренчә, бу инвалидлар спортын тагын да нәтиҗәлерәк үстерергә мөмкинлек бирәчәк. Юбилярның хыялы — инвалид спортчылар белән 2012 елда Лондонда узачак параолимпия уеннарында катнашу.